Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА

2008 ел

# Тикмә кеше гәүһәр кадрен аңлый алмас...

Без бик еш кына «ерактагы кояш яктырак» дип кабатларга яратабыз. Янәшәдәгеләр тәмам «үзебезнекеләргә» әверелә дә, аларга гали итеп түгел, гади итеп карарга күнегәбез. Күр инде, Рәшит абый белән «Мәйдан» журналында ничә ел бергә эшлибез, аны саллы иҗат йөгенә ия әдип булудан бигрәк, гап-гади Бәшәр дип бәялибез түгелме? Хәер, үзе дә «мин-мин, мин кем» дип күкрәк кагып йөрүчеләрдән түгел шул ул. Мал иясенә охшый, диләр бит, аның иҗаты да холкы шикелле – иплән кенә агучы саф чишмәне хәтерләтә. Юлдагы бар нәрсәне вата-җимерә аккан ташкын сулар кебек түгел, тирә-юньне шифалы суы белән сугарып, бертуктамый челтер җыр көйләгән чишмәдәй, тыныч кына, тыйнак кына яза да яза Рәшит абый. Күпләр аны балалар шагыйре буларак белә. «Иртәгә дә яшисе бар», «Миләш», «Ачык капка», «Минем әтиемне сугышта үтерделәр», «Былбыл оясы» кебек повестьлары исә аның оста куллы рәссам-прозаик икәнен дә раслый. Язучыларның барысына да бу дөньяның күзгә күренмәс төсләрен чагылдыру сәләте бирелмәгән, Рәшит абый исә, нәзакәтле рәссамдай, бөтен нечкәлекләрне тоеп, кәгазьгә төшерә белә. Аның һәр җөмләсе кыскалыкта осталык дигән гыйбарәгә тугры һәм яшәешнең нинди дә булса бер канунын үз эченә сыйдыра. Чәчмә әсәрме ул, шигырь, поэмамы – автор үзенең тел матурлыгы, гаҗәеп табышлары, сурәтләү чаралары белән шаккатыра. Әйткәнемчә, аның әсәрләре үзенә охшаган. Рәшит абыйның холкына самимилек һәм шуның белән бергә ныклык хас. Кешегә беркайчан күтәрелеп бәрелмәс, әмма тиешле урында үз сүзен әйтер. «Юк!» дияргә ашыкмас, «ярар» дип ризалашыр, дөрес дип тапканча эшләр. Бу җәһәттән планерка вакытында булган бер мәзәк искә төште әле. Редактор, Рәшит абыйга карап: «Син, Бәшәр, гел ярар-ярар дип кенә утырма анда», – ди, үзенчә кисәтү ясап. «Ярар, ярар», – дип җавап кайтара Рәшит абый... Аны олысы-кечесе шулай үз итеп Бәшәр дип йөртә. Янында кеше өзелми – кемгәдер киңәш кирәк, кемдер үзе язып алып килгәннең шигырьме-түгелме икәнен ачыкларга тели, икенче берәве язмасының классикларны бәреп егарлык икәнен исбатларга маташа...

Рәшит абый балалар белән очрашуларга еш йөри. Заманында Лениногорск районында укытучы булып эшләве сәбәпме, өч оныкка бабай булуымы – һәрберсен авызына каратып кына тора ул. Кәгазьгә күз салу дигәнне белми, шигырьләрен барысын яттан укый. Шаянрак шигырь булса, үзе көлә, күзе көлә, аңа кушылып, балалар көлә. Шул арада җайлы гына итеп әдәп-әхлак сабаклары да биреп ала, сабыйлар аңларлык телдә бүгенге вәзгыять, сәясәт турында да «дәрес бирә». Олырак сыйныф балалары, гадәттә, беренче мәхәббәт турында сорау бирмичә калмый. Алар Рәшит абыйның башлангычта укыганда бер кызга «су буена төш, мин прәннек алып киләм, кимереп утырырбыз» дип хат язуын; булачак тормыш иптәше Люция белән бер сыйныфта укуын, имтиханнар вакытында бер-берсенә күчертмичә «газаплаганнарын» авыз ачып тыңлый. Бәшәрнең шигырьләре дә, сүзе кебек

үк, җәлеп итү көченә ия, аларда ясалмалык юк, киресенчә, дөньяны сабыйларча күрә белү ярылып ята. Геройлары артык сүз сөйләми генә балага сабак бирә: шомырты, якадан каптырып, «каракланма!» ди, әтәче «татарча дәш!» ди, җәй кызы табигатьнең һәр күзәнәгеннән матурлык күрергә өйрәтә, малай исә «мин – татар малае!» дип горурлана. Чаллының балалар бакчаларында, мәктәпләрендә нинди дә булса кичә оештырылса, аларда Рәшит Бәшәр шигырьләре яңгырамый калмый. Андый кичәләрдә, редакция хезмәткәрләре буларак, без дә еш катнашабыз һәм укучыларның, мөгаллимнәрнең Рәшит абыйга булган ихлас хөрмәтен күреп, үзебез дан алгандай, горурланып кайтабыз.

Шәхсән үземнең күңелне тырнаган бер нәрсә бар: Рәшит Бәшәрнең иҗат юлы әдәбият белгечләре тарафыннан әле дә булса читтә калып килә бирә. Аерым авторларның газетада чыккан язмалары, гомуми җыелышларда санап үтелгән исемнәр арасына кертү генә бу фикеремне кире кага алмый. Аның саллы прозасы үзе генә дә аерым игътибарга лаек.

Рәшит абый кемнәндер нидер сорап, теләнеп йөри торган кеше түгел. Үзе өчен берни дәгъваламый, киресенчә, күбрәк башкалар мәнфәгате өчен җан атып яши ул. Без белгәндә генә дә ничәмәничә кешегә иҗат мәйданына ныклап аяк басарга этәргеч бирде! Аның хәерфатихасы белән соңгы елларда гына да Әлфия Ситдыйкова, Сирень Якупова, Айрат Суфиянов, Марат Кәбиров кебек исемнәр укучыларга тәкъдим ителде. Шигърияттә һәм прозада инде билгеле урын биләгән Фирүзә Җамалетдинова аны үзенең остазы дип саный. Минем үземнең дә китабым дөнья күрү – Рәшит абыйның җылы сүзе, таяныч булуы нәтиҗәсе; шуңа күрә хөрмәтем дә, рәхмәтем дә чиксез аңа.

Рәшит абыйның әсәрләреннән дә ниндидер җылылык, сагышлы юмор бөркелеп тора кебек. Аларда – мәңгелек балачак илен сагыну, шуннан китәсе килмәү, шул чактагы күңел сафлыгына омтылу. «Покостагы печән кәнфит кәгазе күк кыштыр-кыштыр килеп тора». Болай дип яза белгән кешене шул илдән киткән дип әйтеп буламы?! Нәкъ менә күңел чисталыгы аңа үз-үзеннән дә көләргә мөмкинлек бирә. Аның турында башкаларның нинди дә булса гайбәт сөйләгәнен ишеткәнем юк, чөнки Рәшит абый үзенең «гөнаһларын», «этлекләрен» көлә-көлә үзе үк сөйләп ташлый. Адәм баласы әүлия түгел, хаталанган, ялгышкан чаклар да булмый тормый. Кайберәүләр үз кылганнарыннан, башын комга яшергән тәвә кошыдай, качуны хуп күрә. Рәшит абыйны исә мин көчле ихтыярлы кеше дип беләм. Үз-үзенә дә, башкаларга да таләпчән ул. Әсәрләре һәм үзе арасында капма-каршылык юк. «Минем туган җиремдәге агачларның да, яңгырда тишкәләнеп-мүкләнеп беткән ташларның да, керәшәләре тыз-быз очып йөргән, ерак-еракларга яшел тасма, юк, яшел кәлтә сыман сузылып-бөтерелеп киткән елганың да милләте юк. Алар бар да туган җиремнеке. Милләте юк, дисәм дә, мин аларга барыбер татарча эндәшәм. Балаларым бу ташлар, бу тугайлар белән нинди телдә сөйләшер?..» Повестьта шулай дип язган Бәшәр чәй өстәле артында утырганда да шундый ук уйлары белән уртаклашырга мөмкин. Рәшит абый еш кына редакциядәге әңгәмәләрнең «тоткасына» әверелә. Тиктормас оныкларының шуклыгыннан башланган сүз йомгагы ахыр чиктә барыбер дөньяви проблемаларга килеп тәртелә: ул балалар бабалары язганны татар телендә укый белерме? Татар әдәбиятын телсез, җансыз, шәрә әсәрләр күмеп китмәсме? Телевизор сәясәте, компьютер белән тәрбияләнеп үскән балаларда милләтнең киләчәге булырмы?..

Рәшит абый еш кына үзенең Казанда

университетта, Мәскәүдә Югары әдәбият курсларында укыган, КАМАЗда эшләгән чакларын искә төшерергә ярата. Игътибар иткәнем бар – кайчандыр яшьлегендә булган кешеләрнең берсен дә ямьсез итеп искә алмый ул. Һәрберсен сагынып, аерым бер җылылык белән сөйли. Әсәрләрендәге геройлар да нәкъ шундый – үз-үзләрен эзләп адашкан Илдарлары, Витькалары да укучыларда нәфрәт уятмый, киресенчә, аларны кызгану, ярдәм итәсе килү теләге пәйда була. Язучының көче – әсәрләрендә үз күңеленең матурлыгы һәм ихласлыгы чагылудадыр, мөгаен... Шулай булмаса, аның бик күп шигыре балалар өчен дәреслекләрдә урын алмас иде. Бу яктан Рәшит абыйны бәхетле дияр идем, китаплары да табадан төшеп кенә тора. Абдулла Алиш исемендәге премия лауреаты дигән мактаулы исеме дә бар. Тугры укучылары – бихисап. Бәлки менә шул укучылар арасыннан киләчәктә аның әсәрләрен тирәнтен өйрәнеп, җитди сүз әйтә алырдайлар үсеп чыгар. Бәлки каләмдәшләре шундый эшкә алыныр... Рәшит Бәшәрнең дөнья әдәбияты җәүһәрләреннән тәрҗемәләре, үзенчәлекле «Былбыл оясы» повесте, намус һәм вөҗдансызлык, сугыш һәм тынычлык темалары үзләре генә дә фәнни эшләргә менә дигән этәргеч.

...Ел башында гына укучылар аның «Җәй кызы» дигән шигырь китабын кулга алып сөенгәннәр иде. Китап тиз арада үз укучыларын тапты, эчтәлеге, хикмәтле бизәлеше белән әсир итте. Һәм... күп тә үтмәде, «Йолдызлы тай» дигән өр-яңа китап Татарстан китап нәшрияты табасыннан төшеп, балаларга янә бер олы бүләк булды. Мавыктыргыч шигырьләр, рәссам Рөстәм Хәбибуллинның кызыклы рәсемнәре сабыйларны гына түгел, олыларны да җәлеп итәргә сәләтле. Һичшиксез, бу китапның да укучылары бихисап булыр. Чөнки шигырьләрдә, әйткәнемчә, мәңгелек балачак иле, аның ваемсыз, самими чагылышы.

...Язмамның максаты Рәшит Бәшәрнең иҗатына анализ ясау яки аның шәхесен шәрехләү түгел. Сүзе һәм үзе бербөтен булып, татар әдәбиятына хезмәт иткән олы шәхес һәм кеше кадере турында уйлануым иде...

## АНЫҢ ТУРЫНДА КАЛӘМДӘШЛӘРЕ

* * *

Рәшит Бәшәрнең көчле ягы – әйләнә-тирәне рәссамча күрә, табигатькә җан өрә белүендә һәм бигрәк тә балалар күңелен аңлый, дөньяга алар күзе белән карый белүендә.

**Саҗидә СӨЛӘЙМАНОВА,**
шагыйрә.
*1975.*

* * *

Хәрәкәт! Вакыйга! Драматургиядәге шикелле, балалар поэзиясенә дә шушы ике нәрсә зарури. Шигырьнең беренче юлларында ук хәрәкәт һәм вакыйга күренми икән, бу – су өстенә рәсем ясарга азаплану белән бер! Рәшит Бәшәрне аерым пьедесталга бастырып куярга җыенмыйм, әмма шунысы хак: аның кечкенә генә шигырьләрендә дә хәрәкәт тыпырдап тора, вакыйгалар агышы өстенлек итә.

**Рашат НИЗАМИЕВ,**
язучы.
*1982.*

* * *

Рәшит Бәшәр балалар әдәбиятында үз юлын тапкан, тавышы ышанычлы, фантазиясе канатлы. Мин аның күбрәк эшләвен, иҗат мөмкинлекләренең киңрәк һәм тирәнрәк ачылуын телим.

**Шәүкәт ГАЛИЕВ,**
Татарстанның халык шагыйре.
*1983.*